ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01 апрель 2021 ел № 2236

Башкарма комитетның «Тышкы мәгълүмат чарасын урнаштыру проектын (паспорт) килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 4 мартындагы 982 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Тышкы мәгълүмат чарасын урнаштыру проектын (паспорт) килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 4 мартындагы 982 номерлы карарына (Башкарма комитетның 2016 елның 29 июнендәге 3347 номерлы, 2019 елның 5 июлендәге 3438 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбулада «Шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 20 сентябрендәге 21/8 номерлы карары, Башкарма комитетның 2013 елның 9 апрелендәге 2393 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеге» сүзләрен «Шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 24 октябрендәге 20/8 номерлы карары, Башкарма комитетның 2021 елның 3 мартындагы 1441 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеге» сүзләренә алмаштырырга;

2) административ регламентта:

- 1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

- «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон (РФ законнары җыентыгы, 27.11.1995, № 48, ст. 4563, Российская газета, № 234, 02.12.1995.);

- Россия Федерациясенең Салым кодексы (икенче өлеш) (алга таба – РФ Салым кодексы) (РФ законнары җыентыгы, 07.08.2000, № 32, статья 3340);

- 2001 елның 25 октябрендәге 136-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Җир кодексы (алга таба – РФ Җир кодексы) (РФ законнары җыентыгы, 29.10.2001, № 44, ст. 4147);

- 2004 елның 29 декабрендәге 188-ФЗ номерлы Россия Федерациясенең Торак кодексы (алга таба – РФ Торак кодексы) (РФ законнары җыентыгы, 03.01.2005, № 1 (1 өлеш), статья 14);

- «Техник җайга салу турында» 2002 елның 27 декабрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - «Техник җайга салу турында» ФЗ) (РФ законнары җыентыгы, 30.12.2002, № 52 (1 өлеш), статья 5140);

- «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (РФ законнары җыентыгы, 06.10.2003, № 40, ст. 3822);

- «Россия Федерациясендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – «Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» ФЗ) (08.05.2006, № 19, статья 2060);

- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыентыгы, 02.08.2010, № 31, ст. 4179);

- Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы законы (алга таба – «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» ТР Законы) (Республика Татарстан, № 155-156, 03.08.2004);

- Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – Устав) (Челнинские известия, №235-237, 10.12.2005; №249-250, 30.12.2005);

- Башкарма комитетның 2017 елның 20 октябрендәге 994-р номерлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе турында нигезләмә (алга таба – Идарә турында нигезләмә);

- Шәһәр Советының 2017 елның 24 октябрендәге 20/8 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре (алга таба – Төзекләндерү кагыйдәләре);

- Башкарма комитетның 2014 елның 11 мартындагы 147-р номерлы боерыгы белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының эш регламенты (алга таба – Эш регламенты);

- Башкарма комитетның 2020 елның 25 февралендәге 101-р номерлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр).»;

- 1.6. пунктта икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тышкы мәгълүмат чарасы – биналарның, төзелешләрнең, корылмаларның, фасадларында, түбәләрендә яки башка тышкы өслекләрендә (тышкы киртә конструкцияләрендә), шул исәптән витриналарны да кертеп, оешма яки шәхси эшмәкәрнең урнашу яки эшчәнлеген гамәлгә ашыру урынында стационар булмаган сәүдә объектларының тышкы өслекләрендә урнашкан, юридик затның исеме, юридик затның эшчәнлек төре (тибы, профиле) турында өченче затларга мәгълүмат бирү

максатларында мәгълүмат урнаштыру өчен билгеләнгән мәгълүмат конструкцияләре. Тышкы мәгълүмат чараларында шулай ук хуҗа булган оешманың товар тамгасы яки хезмәт күрсәтү билгесе урнаштырылырга мөмкин;»;

- 2.6 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 6 пунктча өстәргә:

«6) РФ бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмауны раслый торган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында мәгълүматлар»;

- «Бирү өчен нигезләр» пунктының 2.9. пунктына түбәндәге эчтәлектәге 10 пункт өстәргә:

«10. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булу.»;

- 2.14. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрне кабул итү һәм аларның көтеп тору урыннарына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен уңайлылыгын тәэмин итүгә, андый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматын урнаштыруга таләпләр | 1) муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган бүлмәләрдә һәм биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен истә тотып урнаштырыла.<br>2) инвалидларга тәэмин ителә:<br>- муниципаль хезмәт күрсәтелә торган бинага, бүлмәгә тоткарлыксыз керү (керү һәм аннан чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү, шул исәптән кресло-коляскадан файдаланып);<br>- муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарда, бүлмәләрдә, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналар, бүлмәләр урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;<br>- күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе бозылган инвалидларны озатып йөрү һәм аларга муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарда, бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;<br>- инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, бүлмәләргә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөрткечләрне тиешенчә урнаштыру;<br>- ишетә һәм күрә торган мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны рельефлы-нокталы Брайль шрифтында башкарылган билгеләр белән кабатлау, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;<br>- закон нигезендә билгеләнә торган форма буенча һәм тәртиптә бирелә һәм махсус өйрәтелгән булуын раслый торган документы булганда, муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, бүлмәләргә юл күрсәтүче этне кертү;<br>- муниципаль хезмәт күрсәтә торган оешмаларның хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә муниципаль хезмәттән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү.<br>Әлеге пунктның 2 пунктчасында күрсәтелгән таләпләр бары тик файдалануга яңа тапшырылган яки реконструкцияләнгән, модернизацияләнгән объектларга һәм чараларга гына куела. | 210-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясының 12 пункты; «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы |

- 3.1.2 пункт үз көчен югалткан дип танырга;
- 3.4.2 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар законда билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары И.З. Исхаковка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев